**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет «Тумутукского сельского поселения» Азнакаевского муниципального района**

ул. Тельмана, д.62Б , с. Тумутук
Азнакаевского муниципального района
423316, Тел. (885592) 3-34-42

Электронная почта: Tumut.Azn@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы «Тымытык авыл жирлеге» башкарма комитеты**

Азнакай муниципаль районы, Тымытык авылы, Тельман урамы, 62Б
423316, Тел. (885592) 3-34-42

Электрон почта: Tumut.Azn@tatar.ru

**Постановление** **Карар**
**18 март 2019 ел** **№2**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Тымытык» авыл җирлеге муниципаль берәмлек территориясендә каты коммуналь калдыклар җыю урыннарын (мәйданчыкларны) төзү һәм аларның реестрын алып бару Кагыйдәләрен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законнар, «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы, «Җитештерү һәм куллану калдыклары Турында» федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 31 декабрендәге 503-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең» каты коммуналь калдыкларны җыю һәм аларның реестрын алып бару Кагыйдәләрен раслау турында» 2018 елның 31 августындагы 1039 номерлы карары нигезендә , карар бирәм :

1. Расларга:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Тымытык» авыл җирлеге муниципаль берәмлек территориясендә каты коммуналь калдыклар җыю урыннарын (мәйданчыкларын) төзекләндерү һәм аларның реестрын алып бару кагыйдәләрен, 1 нче кушымта нигезендә;

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Тымытык» авыл җирлегендә каты коммуналь калдыклар җыю урыннарын (мәйданчыкларын) булдыруны, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Тымытык» авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең

Башкарма комитеты белән килештерү турында гариза формасын, 2 нче кушымта нигезендә;

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Тымытык» авыл җирлеге муниципаль берәмлек территориясендә каты коммуналь калдыклар җыелу урыны (мәйданы) турындагы мәгълүматларны реестрга кертү өчен гариза формасын, 3 нче кушымта нигезендә;

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Тымытык» авыл җирлеге муниципаль берәмлек территориясендә каты коммуналь калдыкларны җыю урыннары (мәйданчыклары) Реестры формасын, 4 нче кушымта нигезендә.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында»: http://pravo.tatarstan.ru. веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Азнакай муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә: http//aznakayevo.tatarstan.ru. веб-адрес буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үзем артыннан калдырам.

Башлык Э.Х.Гыйләҗева